Мин Фатыйхова Хазяр Тимергали кызы 1935 елнын 7 августында, Саба районы Туктар авылында сигезенче бала булып доньяга туганмын. 1941 елнын 22 июнендэ сугыш чыкты.Сугыш чыкканда мина 6 яшь иде. Мин абыйларымнын сугышка киткэннэрен, энилэрнен аларны озатып калганнарын эле дэ булса хэтерлим. Абыйларымнын исемнэре Минхажев Гаязетдин 1910 елгы, Минхажев Мохэмэтдин 1912 елгы, Минхажев Билалетдин 1914 елгы иделэр. Абыйларнын икесе ойлэнгэн берсе ойлэнмэгэн иде. Ике абыйнын хатыннары тол, балалары ятим устелэр. Алар шул китулэреннэн туган илебезгэ эйлэнеп кайта алмадылар. Безнен балачагыбыз авыр сугыш елларына туры килгэнлектэн, ачлык, ялангычлык куреп, бер телем икмэккэ тилмереп устек. Безне ач улемнэн черек бэрэнге белэн кычыткан саклап калды. Сугыш беткэннэн сон да, тамагыбыз ипигэ туймады. Сугышка киткэн ир-егетлэрнен бик азы гына эйлэнеп кайтты. Кубесе туган илебезне саклаганда, мэнгелеккэ далада ятып калдылар. Колхоз эшенэ эшче кочлэр житмэгэнлектэн, без балаларны да яшьтэн ук эшкэ жиктелэр. Колхоз эшлэгэнгэ хезмэт коне генэ яза, берт тиен акча тулэми. Шуна барлык халыклар ачлы туклы яшэделэр. Без кыш укыдык, жэй буе эшлэдек. Энилэребез, апаларыбыз, урман кистелэр, вагон тояделэр. Яз коне симэнэгэ дигэн ашлыкны, оек чабата белэн су жырып, жилкэлэренэ капчык кутэреп, станциядан жияулэп ташыдылар . Ара ераклыгы 25 чакрым. Безнен балачагыбыз эш белэн узды. Авырлыкларны жинеп без дэ усеп життек. 1958 нче елны мин Сабанын Котдус исемле егетенэ тормышка чыктым. Минем кайнатам Фатыйхов Йосыф исемле иде. Ул сугышнын беренче коннэреннэн ук китеп, ике ел сугышканнан сон каты яраланып, кулы имгэнеп, госпитальдэ ятканнан сон Сабага кайта алу бэхетенэ ирешэ. Савыкканнан сон аны Мэртен авылына, колхоз рэисе итеп билгелилэр. Ул шунда биш ел буе, намуслы хезмэт башкара. Илебезне торгызуда узенен олешен кертэ. Анын фотосын сезгэ жибэрэбез.

Быел Боек жину коненэ 72 ел тула, шул унайдан шыгырь язып жибэрергэ булдым.

**Боек жинугэ 72 ел.**

Кырык бернен июньендэ

Германия сугыш башлап

Бомба, снарядлар ташлап

Яндырылды авыллар, калалар

Туган илне саклау очен

Утка керде газиз балалар!

Сугышка керде иратлар

Ослэренэ шинель киеп

Каеш белэн буып биллэрен,

Кайнар каннарын койдылар

Дошманнарга бирмэс очен

Бер карышында туган жирлэрен.

Хэр гаилэ кан яшь тугеп
Узлэренен газизлэрен
Сугыш кырына озаттылар
Миллионнаган солдатларын
Бик кубесе ятып калды
Илгэ бик азлары кайттылар.

Илебезнен солдатлары
Кахарманнарча корэшеп
Батырларча хэлэк булдылар,
Бэхетлэр исэн калып
Илгэ Боек жину яулап
Орден, медаль тагып кайттылар.

Боек жину коне буген
Шэхэрлэрдэ, авылларда
Буген бэйрэм-Боек тантана,
Жину жинел бирелмэде
Сугышларнын газаплары
Ойрэклэрдэ хаман саклана

Сугыш куптэн бете
Туган илебездэ
Нурлы таннар атты яктырып
Далаларда ятып
Кайтмый калганнарда
Илебездэ яшилэр таш хэйкэллэр булып

Отытмасак иде
Без якты доньяда
Алар жингэн очен яшибез
Шокерана кылыйк
Бу иркен тормышка алар хормэтенэ
Башыбызны иик!

Хазяр Фатыйхова Тимергали кызы 12.04.17ел.